ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ТАШКИЧИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ АРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Г.Тукая, д. 19,с.Ашитбаш,
Арский муниципальный район 422039

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТАШКИЧҮ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Г.Тукай урамы, 19 йорт,
Ашытбаш авылы,
Арча муниципаль районы, 422039

Тел. (84366)90-2-58, факс (84366)90-3-22. E-mail: Tash.Ars@tatar.ru

**«10» ноябрь 2016 ел** **№ 28**

**Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге муниципаль ихтыяҗлары өчен хезмәт күрсәтүләр, товарлар китерү, эшләр башкару предметы булган контрактларны банк белән тәэмин итүне гамәлгә ашыру очракларын билгеләү турында**

“Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында” 2013 елның 05 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законның 35 статьясындагы 2 өлеше нигезендә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 20.09.2014 № 963 “Контрактларны банк белән тәэмин итү турында”гы карары белән Арча муниципаль районының Ташкичү авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Арча муниципаль районының Ташкичү авыл җирлегенең муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар китерү, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү контрактларын банк белән тәэмин итү "Контрактларны банк белән тәэмин итү турында" Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 20 сентябрендәге 963 номерлы карары белән расланган Кагыйдәләр нигезендә гамәлгә ашырыла:

- контрактның башлангыч (максималь) бәясе, контрактның бердәнбер тәэмин итүче (подрядчы, башкаручы) белән контракт бәясе кимендә биш йөз миллион сум тәшкил итсә, контрактны үтәү кысаларында исәп-хисапларны мониторинглауны уздыруда төзелә торган контрактны банк озата баруларына карата;

- кабул ителә торган товарларның, эшләрнең (аларның нәтиҗәләрен), контракт шартларына хезмәт күрсәтүне (контрактның башлангыч (максималь) бәясе, бердәнбер тәэмин итүче (подрядчы, башкаручы) белән контракт бәясе

кимендә бер миллиард сум тәшкил итсә, банк тарафыннан күрсәтелгән контрактка карата контрактның бәясе бер миллиард сумнан да ким түгел.

2. Заказчылар Арча муниципаль районының Ташкичү авыл җирлегенең муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар китерү, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү контрактларын банк белән тәэмин итү турында карар кабул итәргә хокуклы, контрактның башлангыч (максималь) бәясе бердәнбер тәэмин итүче (подрядчы, башкаручы) белән контракт бәясе кимендә ике йөз миллион сум тәшкил иткән очракта.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru/.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Ташкичү авыл җирлеге башлыгы Ф.Х.Фәйзуллин